СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**29.03.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 282**

Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексын раслау турында

Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җәмгыятьнең ышанычын арттыру, Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тарафыннан муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын намуслы һәм нәтиҗәле үтәү өчен шартлар тудыру, шулай ук Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексын (алга таба - Кодекс) кушымтада каралганча расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә муниципаль хезмәткәрләрне Кодекс белән таныштырырга.
3. Муниципаль хезмәткәрләрнең Кодекс нигезләмәләрен үтәвен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә йөкләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **А. В. Тыгин**

Расланган
Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2018 елның 29
мартындагы 282 номерлы карары
белән

# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ЭТИКАСЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ТӘРТИБЕ КОДЕКСЫ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексы (алга таба – Кодекс) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, муниципаль хезмәткәрләр өчен чикләүләр, тыюлар һәм бурычлар булган башка федераль законнар, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору буенча Совет Президиумының 2010 елның 23 декабрендәге карары белән хупланган Россия Федерациясе дәүләт хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең этикасы һәм хезмәт тәртибе типовой кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып эшләнгән .

1.2. Кодекс Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр) һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар кулланырга тиешле һөнәри хезмәт этикасының һәм хезмәт тәртибенең төп кагыйдәләре җыентыгыннан гыйбарәт.

1.3. Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәткә керә торган Россия Федерациясе гражданы әлеге Кодексның нигезләмәләре белән танышырга һәм үз хезмәт эшчәнлеген башкарганда, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, аларны үтәргә тиеш.

1.4. Һәр муниципаль хезмәткәр Кодекс нигезләмәләрен үтәү өчен барлык кирәкле чаралар күрергә тиеш, ә Россия Федерациясенең һәр гражданы муниципаль хезмәткәр белән аралашканда, аннан Кодексның нигезләмәләрен үтәвен өмет итәргә хокуклы.

1.5. Кодексның максаты – муниципаль хезмәткәрләрнең, үз һөнәри эшчәнлекләрен лаеклы үтәү өчен, хезмәт этикасы кагыйдәләрен һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен билгеләү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең абруен, гражданнарның җирле үзидарә органнарына ышанычын ныгытуга ярдәм итү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең бердәм тәртип нормаларын тәэмин итү.

1.6. Кодекс муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үз вазыйфаи бурычларын башкаруның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән.

1.7. Кодекс муниципаль хезмәт өлкәсендә тиешле әхлак формалаштыру, җәмгыяттә муниципаль хезмәткә карата ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру өчен нигез булып тора, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең иҗтимагый аңы һәм әдәплелеге, аларның үз-үзләрен контрольдә тоту институты буларак та тора.

1.8. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Кодекс нигезләмәләрен белү һәм үтәү, аларның һөнәри эшчәнлеге һәм хезмәт тәртибе сыйфатын бәяләү критерийларының берсе булып тора.

## 2. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенең төп принциплары һәм кагыйдәләре

2.1. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенең төп принциплары муниципаль хезмәттә булуына бәйле рәвештә Россия Федерациясе гражданнарының үз-үзләрен тотышының нигезе булып тора.

2.2. Дәүләт, җәмгыять һәм гражданнар алдында җаваплылык тоеп, муниципаль хезмәткәрләр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

а) вазыйфаи бурычларын намус белән һәм югары һөнәри дәрәҗәдә башкарырга, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә кешенең һәм гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен расага, милләтенә, теленә, дингә һәм башка шартларга карамастан, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

б) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау җирле үзидарә органнары һәм муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең төп мәгънәсен һәм эчтәлеген билгеләүдән чыгып эш итәргә;

в) үз эшчәнлеген тиешле җирле үзидарә органы вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырырга;

г) нинди дә булса һөнәри яки социаль төркемнәргә һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә, аерым гражданнарның, һөнәри яки социаль төркемнәр һәм оешмаларның йогынтысыннан бәйсез булырга;

д) вазыйфаи бурычларын намус белән башкаруга комачаулаучы нинди дә булса шәхси, милек (финанс) һәм башка мәнфәгатьләр йогынтысына бәйле гамәлләрне булдырмаска;

е) законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә, муниципаль хезмәт узуга бәйле вазыйфаларны башкарырга;

ж) сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр карарларының аларның хезмәт эшчәнлегенә йогынты ясау мөмкинлеген кире кагучы битарафлыкны саклау;

з) хезмәт, һөнәри этика нормаларын һәм эшлекле тәртип кагыйдәләрен үтәргә;

и) гражданнар һәм вазыйфаи затлар белән эш итүдә корректлылык һәм игътибарлылык күрсәтергә;

к) Россия һәм башка дәүләтләр халыкларының гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә карата түземлелек һәм ихтирам күрсәтергә, төрле этник, социаль төркемнәрнең һәм конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга, милләтара һәм конфессияара татулыкка ярдәм итәргә;

л) муниципаль хезмәткәрләрнең үз вазыйфаи йөкләмәләрен намуслы башкаруда шик уятырлык гамәлләрдән тыелып торырга, шулай ук аның абруена яисә җирле үзидарә органы абруена зыян китерә алырлык низаглы хәлләрне булдырмаска;

м) мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгуны булдырмау һәм бәхәсләрнең килеп чыгуын җайга салу буенча законнарда каралган чараларны күрергә;

н) шәхси мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен хезмәт урыныннан файдаланмаска;

о) Зеленодольск муниципаль районы Советы, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, җирле үзидарәнең башка органнары эшчәнлегенә карата, әгәр бу муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларына кермәсә, җәмәгатьчелек алдында чыгыш ясаудан, фикерләүдән һәм бәяләүләрдән тыелырга;

п) Зеленодольск муниципаль районы Советында билгеләнгән гавами чыгышлар һәм хезмәт мәгълүматы бирү кагыйдәләрен үтәргә;

р) массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә Зеленодольск муниципаль районы Советы, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы эше турында хәбәр итү буенча эшчәнлекләренә хөрмәт белән карарга, шулай ук билгеләнгән тәртиптә дөрес мәгълүмат алуда ярдәм күрсәтергә;

с) халык каршында чыгышларда, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында, Россия Федерациясе территориясендә чит ил валютасында (шартлы акчалата берәмлекләрдә) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр һәм граждан хокукларының башка объектлары бәясен – Россия Федерациясе резидентлары арасында килешүләр суммасы, Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗә бюджетлары күрсәткечләре, муниципаль бурычка алу күләмнәре, муниципаль бурыч күләмен билгеләүдән тыелып торырга, бу мәгълүматны төгәл тапшыру өчен кирәк булган яисә Россия Федерациясе законнары, Россия Федерациясе халыкара килешүләре, эшлекле әйләнеш традицияләре белән каралган очраклардан тыш;

т) яллаучы (эш бирүче) вәкиленә, прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына коррупцион хокук бозулар кылуга омтылу максатында муниципаль хезмәткәргә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итүенең барлык очраклары турында хәбәр итәргә;

у) җаваплылык даирәсендәге ресурслар белән мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк эш итүне тәэмин итүгә даими омтылырга.

2.3. Муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституциячел һәм федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлек Уставын, муниципаль хокукый актларны үтәргә тиеш.

2.4. Муниципаль хезмәткәрләр, сәяси, икътисадый максатка ярашлылыгыннан чыгып йә башка мотивлар буенча законнар һәм башка норматив хокукый актлар бозылуга юл куймаска тиеш.

2.5. Муниципаль хезмәткәрләр коррупция күренешләренә каршы торырга һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аны профилактикалау чараларын күрергә тиеш.

2.6. Муниципаль хезмәткәрләр үзләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуларына юл куймаска тиеш.

Муниципаль хезмәт вазыйфасына һәм вазыйфаи бурычларын үтәүгә билгеләнгәндә муниципаль хезмәткәр үз вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясый торган яисә йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынуы булуы яисә булу мөмкинлеге турында белдерергә тиеш.

2.7. Муниципаль хезмәткәр үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырырга тиеш.

2.8. Муниципаль хезмәткәр Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органында законнар нигезендә, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән нормаларны һәм таләпләрне үтәгәндә, хезмәт мәгълүматын эшкәртә һәм тапшыра ала.

2.9. Муниципаль хезмәткәр, санкцияләнмәгән рәвештә игълан итү өчен җаваплы булган яисә (һәм) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган мәгълүматның куркынычсызлыгын һәм конфиденциальлеген тәэмин итү буенча тиешле чаралар күрергә тиеш.

2.10. Оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәрләр башка муниципаль хезмәткәрләргә карата профессиональлек, мактауга лаек репутация үрнәге булырга, үзе муниципаль хезмәте вазифасын биләгән Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органында әхлакый - психологик климатның нәтиҗәле эшләве өчен уңайлы булган муниципаль хезмәтнең формалашуына ярдәм итү.

2.11. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

а) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу чараларын күрергә;

б) коррупцияне кисәтү чараларын күрергә;

в) муниципаль хезмәткәрләрне сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегендә катнашуга мәҗбүр итү очракларына юл куймаска.

2.12. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр үзенә буйсынган муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциячел үз-үзләрен тотышын куркыныч астына куймауларына чаралар күрергә, үзенең шәхси тәртибе белән намуслылык, турылык һәм гаделлек үрнәге күрсәтергә тиеш.

2.13. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр, Россия Федерациясе законнары нигезендә, әгәр ул мондый гамәлләргә яки эшсезлеккә юл куймау буенча чаралар күрмәгән булса, үз карамагындагы хезмәткәрләрнең этика принципларын һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен бозулары өчен җаваплы.

2.14. Муниципаль хезмәткәр мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру турында белешмәләр тапшырырга тиеш. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында белешмәләр тапшыру «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 3. Муниципаль хезмәткәрнең коррупциягә каршы үз-үзен тотышы стандарты

3.1. Муниципаль хезмәткәрләр коррупция күренешләренә каршы торырга һәм аны профилактикалау буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә чаралар күрергә тиеш.

3.2. Муниципаль хезмәтвазыйфасына билгеләнгәндә һәм вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, муниципаль хезмәткәр вазыйфаи бурычларны тиешенчә үтәүгә йогынты ясарлык шәхси кызыксынуы туу мөмкинлеге турында белдерергә тиеш.

3.3. Муниципаль хезмәткәр үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Россия Федерациясе законнары нигезендә белешмәләр тапшырырга тиеш.

3.4. Муниципаль хезмәткәр үзен яллаучы вәкиленә, Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына яки башка дәүләт органнарына аңа нинди дә булса затлар коррупциячел хокук бозуга тарту максатларында мөрәҗәгать итүе турында хәбәр итәргә тиеш.

Коррупциячел хокук бозуларны кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамә, әлеге фактлар буенча тикшерү уздырылган яисә үткәрелә торган очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычы булып тора.

3.5. Муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссудалар, матди характердагы хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорттан файдаланган өчен түләү һәм башка бүләкләү) алу тыела. Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәргә алынган бүләкләр муниципаль район милке дип таныла һәм муниципаль хезмәткәр , үзе муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торган җирле үзидарә органына акт буенча тапшыра, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш.

3.6. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләргә бурычлы:

а) башка түләүле эш башкару нияте турында яллаучы вәкиленә алдан хәбәр итәргә;

б) яллаучы вәкиленнән түбәндәгеләргә язмача рөхсәт алырга:

әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана торган түләүле эшчәнлеккә;

әгәр муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларына күрсәтелгән оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек керсә, чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, шулай ук сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни берләшмәләрдән тыш) алуга;

в) муниципаль хезмәткәрнеке булган кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), алар белән эш итү мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булган очракларда, Россия Федерациясе законнары нигезендә ышанычлы идарәгә тапшырырга;

г) матди-техник һәм башка тәэмин итү чараларыннан, башка муниципаль мөлкәттән вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә генә файдаланырга.

3.7. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәрләр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

а) үз кул астындагыларның мәнфәгатьләре конфликтын булдырмау һәм җайга салу чараларын күрергә;

б) буйсынучылар арасында коррупцияне кисәтү чараларын күрергә;

в) муниципаль хезмәткәрләрне сәяси партияләр һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегендә катнашуга мәҗбүр итү очракларына юл куймаска.

3.8. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-күрсәтмә бирү вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәрләр үз-үзләрен тотышлары белән намуслылык, гаделлек һәм турылык үрнәге күрсәтергә тиеш.

3.9. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрләр арасында бер-берсенә турыдан-туры буйсынган якын туганлык (ата-аналары, ире яки хатыны, балалары, абый-сеңелләре, шулай ук иренең яки хатынының бертуганы, сеңелләре, ата-аналары һәм балалары) булганда аларның берсе муниципаль хезмәттән китәргә яисә муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчәргә тиеш.

## 4. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе буенча тәкъдим ителгән этик кагыйдәләре

4.1. Муниципаль хезмәткәр үз хезмәтендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре иң кадерле әйбер булып тора һәм һәр гражданин шәхси тормышның кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, намусын, абруен,яхшы исемен яклауга хокуклы дигән конституциячел нигезләмәләрдән чыгып эш итәргә тиеш.

4.2. Хезмәт тәртибендә муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләрдән тыела:

а) җенес, яшь, раса, милләт, тел, гражданлык, социаль, милек яки гаилә хәле, сәяси яки дини өстенлекләр билгеләре буенча дискриминацион характердагы теләсә кайсы төр сүзләрдән һәм гамәлләрдән;

б) дорфалыктан, кимсетүле тоныннан, тәкәбберлектән, урынсыз кисәтүләрдән, хокуксыз, нигезсез гаеп ташлаудан;

в)нормаль аралашуга комачаулаучы яки хокукка каршы гамәлләргә китерүче янаудан, мыскыллы сүзләрдән, репликалардан, гамәлләрдән;

г) киңәшмә, әңгәмә, гражданнар белән башка хезмәт аралашуы вакытында тәмәке тартудан.

4.3. Муниципаль хезмәткәрләр үзләренең хезмәт тәртибе белән коллективта эшлекле мөнәсәбәтләр урнашуга һәм бер-берсе белән конструктив хезмәттәшлеккә ярдәм итәргә тиеш.

Муниципаль хезмәткәрләр гражданнар һәм хезмәттәшләр белән аралашканда әдәпле, ягымлы, корректлы, игътибарлы булырга һәм түземлелек күрсәтергә тиеш.

4.4. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәт шартларына һәм хезмәт чарасы форматына карап, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә тышкы кыяфәте гражданнарның җирле үзидарә органнарына карата ихтирамлы мөнәсәбәтенә, рәсмилек, тыйнаклык, традиционлык, төгәллек белән аерылып торган гомуми кабул ителгән эшлекле стильгә туры килергә тиеш.

## 5. Кодексның нигезләмәләрен бозган өчен җаваплылык

5.1. Муниципаль хезмәткәрләрнең әлеге Кодекс нигезләмәләрен бозуы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында әхлакый хөкем ителергә тиеш, ә законнарда каралган очракларда Кодексны бозу муниципаль хезмәткәргә карата юридик җаваплылык чараларын куллануга китерә.

5.2. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Кодекс нормаларын үтәү аттестацияләр үткәргәндә, югары вазифаларга күрсәтү өчен кадрлар резервын формалаштырганда, шулай ук дисциплинар җәза биргәндә исәпкә алына.